СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

18 гыйнвар, 1997ел. ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 6 (8018) | Бәясе билгеләнгәнчә

## БЕЗ ҺИЧКЕМНӘН КИМ ТҮГЕЛ

### М.ШӘЙМИЕВНЫҢ АБРУЕ КҮТӘРЕЛӘ

«Vox populi» җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү хезмәте «Независимая газета» белән берлектә һәр айны Россиянең иң көчле 100 сәясәтчесен билгели. Декабрь нәтиҗәләре буенча Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев 18 нче урынга күтәрелде. Ноябрь йомгаклары буенча ул 21 нче иде әле.

Бераз тәнәфестән соң республика Дәүләт Советы Рәисе В.Н.Лихачевны да бу исемлектә күрәбез. Ул Россиянең Үзәк сайлау комиссиясе рәисе А.Иванченко белән 99 - 100 нче урыннарны бүлешә.

Декабрьдә Борис Ельцинның Россия сәясәтенә йогынтысы өченче урын белән бәяләнле. Иң алдагы ике урында Виктор Черномырдин белән Анатолий Чубайс. Экспертлар 23 декабрьдә генә Кремльгә эшкә кайткан Б.Ельцинның ноябрьдә тупланган баллын 0,83кә киметтеләр.

Үткән айда Президентның элеккеге куркынычсызлык хезмәте башлыгы Александр Коржаковның, Курск өлкәсе губернаторы Александр Руцкойның рейтингы бер баллга якын кимеде. Ичкерия Республикасы президентлыгына кандидатларның берсе Шамил Басаев, «Зеркало» телепрограммасын алып баручы Николай Сванидзе, «Московский комсомолец» газетасы баш мөхәррире Павел Гусев, оборона министры урынбасары Владимир Семенов иң көчле йөз сәясәтче арасына беренче тапкыр кертелделәр.

Елның соңгы аенда «Интерфакс» агентлыгы җитәкчесе Михаил Комиссар, Чувашия Президенты Николай Федоров, Дәүләт Думасы депутатлары Станислав Говорухин һәм Николай Рыжков, «Завтра» газетасы баш мөхәррире Александр Проханов, Санкт - Петербург губернаторы Владимир Яковлев, Мәскәү өлкәсе хакимияте башлыгы Анатолий Тяжлов исемлектән төшеп калдылар.

### Хат

### БУЛА ИКӘН БИТ

Яңа ел бәйрәме тирәләрендә гомердә булмаганча әкияти итеп бизәлгән шәһәребезнең үзәк мәйданы, төрле микрорайоннар, урамнарга чыгу да күңелле иде. Боз лабиринтлары, әкият персонажлары сыннары, таган - шугалаклар, төрле төсләр белән җемелдәгән утлар һава торышы кырыс булганда да безне урамга чакырып торды. Ә шәһәр үзәгендә бизәлгән чын чыршы... Барысы да игътибар үзәгендә булды. Чыршы тирәсендә оештырылган уеннар күпме булды тагын... Ә бит башка елларда да бу чараны үткәрүгә финанс бүленә, әмма аны оештыру тамга өчен генә була, акчасы түрәләрнең мөһимрәк «тишекләрен» каплауга тотыла иде. Быелгы чыршы бәйрәме исә безгә районыбызның күпме яшь талантларын ачарга ярдәм итте. Баксаң, бездә сыздырып гармун уйнаучылар да, күңел кылларын тибрәтерлек итеп җырлаучылар да, очып - очып биючеләр дә күп икән. Аларны ачып, зур сәхнәгә чыгарырга, үзешчән артистларыбызның ходай биргән талантларын ача белергә генә кирәк икән бит. Югыйсә, бездә сәләтле кешеләр юк, дигән сүзне еш ишетергә туры килә. Гомумән, районның бүгенге җитәкчелегеннән канәгать, без. Берничә айда ук аларның халык мәнфәгатьләре турында кайгыртуын тойдык. Район мәдәният йортында үткән төрле халыкларының милли кичәләре дә шуңа дәлил. Теләгебез бер. Киләчәктә дә шулай дус - тату яшик, бер - беребезнең мәдәниятын бәялик, хөрмәт итик. Иң мөһиме, үз арабызда гына «йомылып» калмыйча, республика дәрәҗәсенә дә чыгыйк, октябрьлеләрнең эшкә генә түгел, һәрнәрсәгә сәләтле булуын күрсәтик.

Барлыгы 6 имза.

### Петр шәһәрен барып күрделәр

Шәһәр мәктәпләреннән 67 укучы кышкы каникул чорында өч группа булып Санкт - Петербург шәһәренә экскурсия ясадылар. Дөньяның иң матур шәһәрләреннән берсе булган кала балаларны ак кары белән генә түгел, матур җемелдәгән яңа ел чыршылары белән дә каршы алды. Укучылар Эрмитаж, Исаакий соборы, Петропавел крепосте, Аврора крейсеры белән таныштылар, кунсткамерада, зоомузейда булдылар. Һәм, билгеле инде, А.С.Пушкин укыган лицей, Екатерина Сарае да укучылар күңелендә озак онытылмаслык булып истә калды.

Экскурсантлар берочтан өч сәгать буе Мәскәүне дә карап йөрделәр.

Г.КОРЧУКОВА.

### Авыл язны көтә

### Ашламага урын түрдән

«Төрнәс» крестьян хуҗалыклары ассоциациясендә элегрәк минераль ашламалар кайда мөмкинлек булса, шунда саклана иде. Җиргә сибелеп, бозылып яткан чаклары да булды. Ә менә быелдан кыйммәтле булган басу сыена игътибар үзгәрде. Төрнәс бүлекчәсендә узган ел сенаж башнясыннан үзгәртеп корылган складка стеллажлар ясап, ашламаны штабельләп өеп куйганнар. Бина коры, нык. Ашламаны саклау өчен җаваплы склад мөдире Фәнил Соруров та капчыктагы бер генә грамм ашламаны да әрәм - шәрәм итмәү өчен тырыша. Ә монда ашлама аз түгел. Барлык запасның 70 проценты бирегә тупланган. Ашламаларның калганы исә бүлекчәләр складларында саклана. Анда да аның ышанычлы сакланышы тәэмин ителә.

Р.МИНАПОВА.

### Тимерчегә дә шарт кирәк

Элегрәк иске бинада урнашкан тимерчелек алачыгында хезмәт шартлары да начар иде. Шуны истә тотып, хуҗалык мастерское территориясендә ике катлы бина салынып ята. Киләчәктә аның бер өлешендә тимерчелек цехы урнашачак, икенчесе - авыл хуҗалыгы техникасы, иң элек тагылма инвентарьлар ремонтлауга исәпләнгән. Ә бинаның икенче катында механизаторлар йорты булачак.


Объект төзүче - техник Сәлим Йосыповның ныклы контроле һәм җитәкчелеге астында төзелә. Быел ул файдалануга тапшырылачак.

П.ИЛЮХИН.
Салдакай авылы.

### Сездән - йон - бездән - киез итек

Хәзер үз хәле бик җиңелләрдән булмаса да, райпоның хәзерләүләр конторасы коллективы халыктан тире чималы һәм авыл хуҗалыгы продукциясе кабул итүне оештыру чараларын күрә. Былтыр 3 меңнән артык мөгезле эре терлек, 2500дән күбрәк дуңгыз, 5780 вак җәнлек тиресе, 250 центнер чиста җепсел йон һәм башка чимал кабул ителде. Алар эшкәртү өчен Казан, Инза, Киров шәһәрләрендәге фабрика һәм комбинатларга озатыла, алардан каршы сәүдә өчен өлешчә товарлар да кайтартыла. Әйтик, тиздән контораның кибетендә Казан киез итек комбинатының хәзер иң кирәк товары сатуга чыгачак. Үз янындагы «Кара - каршы сәүдә» кибетеннән тыш контораның тагын Октябрьская урамында «Авыл хуҗалыгы продуктлары» кибете һәм шәһәр базарында ларегы бар.

### Хезмәтләре белән мактаулылар



Мансурның берүзенә өч техникасы бар. Җирләр ачылып, кырлар яз сулышы белән яши башлагач, ул үзенең Т - 70 тракторына утыра. Көздән әзерләп калдырган тигез басуга чөгендер орлыклары күмдерә ул аның белән. Күптәннән бу эш белән шөгыльләнгәнлектән, аның җаен да белә, ел үзенчәлекләреннән чыгып таләпләрен дә җиренә җиткереп үтәргә тырыша.

Басуларда игеннәр өлгергәч, башаклар шыгырдап торган тук бөртекләре белән менә - менә игенче кулына егылырга торганда Мансур кыр корабында игеннәр иленә юл тота. 10 еллап инде ул авылдашлары үстергән икмәкне җыя: йокысын - ялын оныта, тынычлыгын җуя, игеннәрнең соңгы көлтәсе суктырылып амбарларга салынмыйча кырдан китми. Быел Мансур мәһабәт «Дон - 1500» не үзләштерде. Акыллы комбайнның авыл кешесенә шулкадәр уңайлык китерүенә куана - куана эшләде ул.

Игеннәр җыелып, авыл кешесе икенче урак - чөгендер алуга керешкәч, Мансур үзенең өченче техникасы - француз комбайнына утыра. Анысын икенче ел иярли механизатор. Берьюлы өч операцияне башкаручы бу камил техниканы районда эшләүче француз белгечләре ярдәмендә үзләштерде. Чөгендерне казый, чистарта, төйи торган комбайнны күргәч, башта авылдашлары хәйран калган иделәр: янәсе, ай - һай, бездә эшләр микән бу француз чибәркәе?! Эшләде тагы! Бары тик пычрак участокларда гына үзләренең сабыр - түзем КС - 6 ларын җибәргәләделәр. Аның каравы, «Правда», Кузнецов исемендәге КХАларга ярдәмгә бардылар. Француз технологиясе буенча игелә торган 170 гектар мәйданны бәлки кайчандыр тулысы белән җыяр көннәр дә җитәр. Акрын гына, әмма төпле генә өйрәнеп - үзләштереп киләләр бит яңа ысулны. Француз сиптергеченда эшләүче Газинур Ганиев та хәзер техникасы белән эш иткәндә аптырап калмый. Билгеле, районда эшләүче француз белгечләре бер дә күздән ычкындырмадылар әлегә алар эшен, һәр көнне килеп, кирәкле киңәшләрне биреп тордылар. Шуңа чөгендер уңышы да начар булмады: гектарыннан физик авырлыкта 285 центнер татлы тамыр алдылар хафизовлылар.

Ул көннәр артта калды. Мансур һәр ике комбайнын да кышкы саклауга куйды. Инде үзе дә ял итәдер дисезме? Ашыкмагыз! Мансур янә техникада. Кышкы чорда ул тракторы белән терлекчеләр карамагында була. Өйрәнелгән гадәт буенча эшен җиренә җиткереп башкара, техникасын сак тота. Шул гадәтләре булмаса, аңа өч техника, аеруча француз комбайнын тапшырырлар идемени? Димәк, иң ышанычлылар, иң булдыклылар исәбендә Хафизов исемендәге ассоциациядә Мансур Насыйбуллин.

С.НУРУЛЛИНА.

Рәсемдә: Хафизов исемендәге хуҗалык механизаторы М.Насыйбуллин.

### ҮТЕРҮЧЕЛӘР КУЛГА АЛЫНДЫ

1996 елның 27 сентябренә каршы төндә НРРЭС (подстанция) территориясендә пычак белән күпсанлы җәрәхәтләр ясап эшмәкәр А.Х.Маняпов һәм каравылчы А.Г.Мурасина үтерелгәннәр иде.

Шул ук елның 31 нче октябренә каршы төндә Яна Иглай авылында алдагысына охшаш юл белән ирле - хатынлы Бикмаметовларны үз өйләрендә үтереп чыктылар.

Район эчке эшләр бүлеге рәсми рәвештә шуны белдерә: бу җинаятьләр ачылды, җинаятьчеләрнең кем булуы ачыкланды. Аларның бу җинаятьләрне эшләүдә гаепле булулары тулысынча расланды.

Җинаятьләр бер төркем тарафыннан эшләнгән, шуларның берсе үтерүләрнең икесендә дә катнашкан. Барлык җинаятьчеләр дә кулга алынды. Аларның өчесе Норлаттан, калганнары Зеленодол һәм Лениногорск шәһәрләреннән булып чыкты.

Без бу авыр җинаятьләрне ачуда милициягә ярдәм иткән барлык гражданнарга рәхмәт белдерәбез.

Район эчке эшләр бүлеге.

## Тирәбездә яхшы кешеләр

# УРТАК ЭШ ДИП ЯНУЧЫЛАРДАН

Һәр кешенең тормыш юлында үзенә генә билгеле, истә калырлык үзенчәлекле вакыйгалары буладыр, мөгаен. Электр - техник җиһазлар ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүнең Әлмәт үзәк базасының Норлат участогы (ЦБПОРЭТО) слесарь - ремонтчысы Әмирҗан Сәмигулла улы Нәбиуллинның 1951 нче елда әле 14 яшьлек яшүсмер килеш туган авылы Яңа Үзидә трактор рычагы артына утырган көннәре һаман да исендә. 16 ел җир сөрде, икмәк үстерде ул. Тиз эшләде, тырыш булды, эшенең бөтен нечкәлекләрен үзләштерде. Тора - бара тәҗрибәсе дә, җитезлеге дә артты. Чит җирләрдә дә йөрде: «Иртышканалстрой»да бульдозерчы, экскаватор машинисты - бер сүз белән әйткәндә, берничә механизаторлык һөнәрен оста башкаручы чын - чынлап техника хуҗасы буларак хезмәт биографиясе формалашкан дип уйларга була аның. Һәм, әйтергә кирәк, нык, нигезле булып.

Бирегә эшкә ул участок оешуга ук килде. Төп эшчәнлеге «Норлатнефть» НГДУсына сервис хезмәте күрсәтүдән гыйбарәт булган һәм электр двигательләре, генераторлар һәм башка төр җиһазларны капиталь ремонтлауны тәэмин итүдән торган оешмада слесарь Нәбиуллинның квалификацияле, ышанычлы һәм намуслы, шул ук вакытта ачык, киң күңелле булуын һәм һәркемгә җылы мөнәсәбәтен тиз арада белеп алдылар.

... Капиталь ремонт цехы үзенең гадәти, шул ук вакытта үзенчәлекле тормышы белән яши. Участок начальнигы Вячеслав Владимирович Вульфсон коллектив эшчәнлегенең үзенчәлекләре, аның көндәлек эшләре турында сөйли, кешеләр белән таныштыра, электротехник корычны кисү һәм «шәрә» электр үткәргечне тышлау өчен цех осталары конструкцияләгән станокларны күрсәтә. Электр двигательләреннән тыш, биредә өлешчә эретеп ябыштыру һәм 250 киловатт куәтле көчәнешле май трансформаторларын ремонтлау, зур трансформаторларга ревизия үткәрелә. Кыздырылган металл исе килә...

... Участоктагы технологик чылбырның барлык буыннары да автоматлаштырылган: электр двигателенең сафтан чыгу сәбәбе билгеләнгәч, ул сүтелә, аннан чорнаучыларга керә, беренчел сынау үтә, лак сеңдерелә һәм киптерү камерасына урнаштырыла. Соңрак - слесарьларның җыю өстәленә, аннан инде сынау стендына урнаштырылып, тиешле булган барлык параметрлар буенча тикшерелә. Шушы еллар эчендә слесарь Нәбиуллин кулы аркылы йөзләгән берәмлек электр җиһазлары үтә, ә аның «профессиональ» күзе һәм эчке сиземләве двигательнең туктап калу сәбәбен тиз күреп ала. Ул үзе теге яки бу эшчегә киңәшен һичкайчан кызганмый.

Дусларча терәк, үзара ярдәмләшү, ышанычлылык - аның өчен иң мөһиме.

Ә Әмирҗан Сәмигуллович турында коллектив ни уйлый?

- Акыллы, уйлап эш итүчән, төгәл, үзенә һәм башкаларга таләпчән - Нәбиуллин характерын шулар билгели,- аның турында бертавыштан шулай диләр,- эшлекле, ачык күңелле. Җыелышта тәнкыйть белән чыгыш ясарга мөмкин - барысы да эш, уртак файда өчен бит. Шундый кешене ничек хөрмәт итмисең инде?

Ә Нәбиуллинның үзе белән без ул көнне очраша алмадык. Ни эшләмәк кирәк, кайчак кыска гына очрашу вакытында кеше ачылып китми, ә аның турында иптәшләре белән сөйләшү журналистка алдан хәзерләнгән очрашудан күбрәк мәгълүмат бирергә мөмкин... Алар аркылы Нәбиуллинның гөмбә җыярга яратуын һәм барлык җиләкле урыннар турында да хәбәрдар булуын белдек. Яхшы компаниядә күңелле истәлекләр дә сөйли, урыны белән мәзәген дә кыстырып җибәрә. Ә яздан кара көзгә кадәр көне - төне үзенең бакчасында казына - хатыны Наҗия Биктимеровнаның сәламәтлеген саклый. Медицина училищесын тәмамлап килгән фельдшер кыз белән танышкан көннән гел бергә алар.

...20 нче гыйнварда Әмирҗан Сәмигулловичка 60 яшь тула. Бу көнне аларның өйләренә көтеп алынган кунаклары, иң беренче булып әтиләрен котларга дип гаиләләре белән уллары Мансур һәм Альберт килерләр. Илдар, Марат һәм Регина бабаларын кысып - кысып кочакларлар, ә эшсез торырга күнекмәгән Наҗия апа бәйрәм өстәленә гаилә өчен традицион булган бишбармак пешерер. Ә тостлар әтиләре һәм әниләре, аларның күңел тынычлыгы, иминлек һәм җан җылылыгы өчен булыр.

**Т.НАЗАРОВА.**

## Тел һәм милләт

# «Бездә татарлар йоклаганмы, әллә...»

Үткән елда «Дуслык» газетасында басылып чыккан «Теле барның иле бар» мәкаләсе күпләр күңелендә зур кызыксыну уяткандыр, мөгаен. Гаҗәп түгел, чөнки анда күтәрелгән проблема - туган телгә карата тискәре караш яшәве, телеңнән хурлану мәсьәләсе уйлый, фикерли торган кешене борчымаслык түгел шул. Бу мәкаләдә бер ханым баласын туган телдә укытырга теләмичә, рус телендә белем биреп, шул телгә карата мәхәббәт хисләре тәрбияләп үстерергә тели. Я, җәмәгать, болай булгач, без, татарлар кая барабыз? Ә бит районыбызда яшәүче татарлар башка милләтләр белән чагыштырганда халыкның күпчелеген тәшкил итәләр. Республика күләмендә бүген татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү хакында сүз алып барыла, ә безнең районда кайбер ата - аналарда үз телләренә карата шундый кимсетүле караш яши. Күбрәк тел белүең үзең өчен, акылың камилләшүе өчен файдалы бит, югыйсә. Үз телеңне, рус, чуваш телләрен өйрән! Аңа карап адәм баласы фәкыйрьләнми, киресенчә, дөньяга карашы киңәя, [illegible]ып - белү сәләте активлаша. Һәм [illegible] очракта, ана телен өйрәтергә теләмәүче кешеләр наданлыкларын гына күрсәтәләр, дип уйлыйм мин.

Бу уңайдан башка бер мәсьәләгә дә бераз кагыласым килә. Ел азагында районыбызда шаулап - гөрләп «Чуваш сандугачы» дип исемләнгән республика зона смотры, шул исәптән фронтовик шагыйрь Елизар Абакшинны искә алу кичәсе дә булып үтте. Әфарин, чуваш туганнарыбыз! Ичмасам, үз моңыгызны башка регионнарга кадәр җиткерергә дә сәләтле бит сез. Безнең татар концертларын күрсәгез, нинди бәя бирер идегез икән? Ул концертларда я микрофоннар «җырлаттырмый», я җырлары төссез, шыксыз булып, халыкны туйдыра башлый. Күбесенчә алар моңсыз, ясалма булалар. Юкмыни соң бездә түбәтәен кыңгыр салып, моңлы тальян гармунда сыздырып, күңелләрне сызландырып уйнаучылар һәм шул ук көйгә кушылып җырлаучылар?! Бар алар, бар, тик аларны күрә белүчеләр генә юк. Нигә чын милли бәйрәмнәр ясамаска, шигъри кичәләр оештырмаска. Темалар да юк түгел бит, әйтик, якташ шагыйребез, рәссам Гакыйль Сәгыйровка багышланган кичә үткәрергә мөмкин. Әйе, милли моңны тоеп, шундый ук мохиттә яшәмәгәч, безнең районда чын милләтпәрвәрләр булуы һәм тәрбияләнүе бик шикле.

Инде яңадан югарыда искә алынган мәкаләгә кире кайтып шуны әйтәсе килә: сез, ханым, бигрәк тә кызганыч тоелдыгыз миңа. Мәкаләдә чыгыш ясаган Н.Абдуллин, К.Җамалетдинова иптәшләрнең акыллы, төпле фикерләре бәлки аз гына булса да күңелегезне «эретерлек» нур салганнардыр, дип ышанасы килә. Нәкъ алар әйткәнчә, балаларыбызны туган телдә тәрбияләп үстерсәк кенә без киләчәктә Кол Галиләр, Габдулла Тукайларга тугрылыклы буын тәрбияли алырбыз. Карап торып нәселе - нәсебен, телен - илен белми торган маңкорт балалар үстермисе иде, җәмәгать!

Язмамның азагында Тукаебызның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дип әйтелгән соравына ияреп мин: «Безнең Октябрь районы татарлары үлгәнме, әллә...» дип сорыйсы килә. Ничек уйлыйсыз, газета укучы дуслар, бу күп нокталар урынына нинди сүзне куйсак урынлы булыр икән?

**З.ГАЛИУЛЛИНА.**
**Бикуле авылы.**

# УЛЫ - КӨРӘШЧЕ, ӘТИСЕ - КИҢӘШЧЕ



... Ата улыннан озак вакыт күзен ала алмыйча торды. Ә йөрәге читлегеннән очып чыгарга җыенган кош сыман дөпелдәп - дөпелдәп типте: бермәлгә янәшәдә авыз эченнән дога укучы хатыны Суфия, дер калтырап басып торучы кызы Фаилә белән дә карашлары очрашты. Алар аңлаштылар: барысы да Фәнил өчен борчылалар. Менә - менә көндәше улларын келәмгә «сылар» төсле тоелды. «Юк, җиңел генә бирелмәс, әтисе улы бит ул», - дип уйлап куюы булды Сәлимҗанның, Фәнил көндәшен күтәреп алды да аркасына яткызды.

- Молодец, улым, булдырдың!

Ата кеше ашыга - кабалана сабантуй түгәрәгенә йөгереп чыкты да, улының тирләгән күкрәгенә барып капланды. Менә ул аның улы, менә ышанычы, терәге... Күңеле йомшарды, тавышы карлыкты, ихтыярсыздан күзләрен яшь пәрдәсе каплады.

... Бер - бер артлы дөньяга килгән улларына бик сөенгән иде Сәлимҗан. Ул чакта үзенең шулай сабантуйларда бил алышып, гайрәтләнеп йөри торган чагы иде әле. Дүртесенең берсе булса да көрәшче булыр, дип күңелен юата килде ата кеше. Аны сөендереп, нык буынлы таза булып үстеләр малайлар. Әллә инде яшьли «ватылмасыннар» дип, әллә башка сәбәпле, Сәлимҗан аларны үсмер чакларында көрәшкә чыгармады. Ә менә Фәниле хәрби хезмәттән кайткач исә, аның ирләрчә ныгыган төз гәүдәсенә сокланып, көрәшеп карарга тәкъдим итте. Бакча артына салам җәеп, башта ике улын көрәштерде. Моңа кадәр «уйнап» кына бил алышып тигез көрәшүче абыйсы Галимҗанны бик тиз җиргә сылады Фәнил.

- Булдырасың, улым. Хәзер икәү көрәшеп карыйк. Әгәр дә мине җиңә алсаң, быел район сабан туена чыгасың да батыр каласың, - диде ата кеше аннан өстәде - күңелем сизә...

Ата күңеле ялгышмады: шул елны 22 яшьлек Фәнил бөтен районны шаккатырып Сабантуй тәкәсен җилкәсенә салды. Фәнилнең көрәшче буларак биографиясе шулай башланды. ДОСААФта инструктор булып эшли иде ул бу чакта. Көне - төне шөгыльләнүе бушка китмәде: икенче елны да чемпион исемен ныгытты ул. Ә менә өченче, ягъни 1989 нчы елда... Сынатты, дусты Фаик Хаҗиморатов җиңүче булды ул елны. Аның каравы, 1990 нчы елдан алып, быелгача дүрт сабан туйда батыр калды. Шушы чорда тагын 2 тапкыр көзге уеннарның милли көрәш батыры булды. Ә инде төрле авылларда, зона ярышларында ничә тапкыр катнашып, күпме егетләрне келәмгә ятырга мәҗбүр итүен үзе дә хәтерләп бетерми хәтта. Сиксәненче елларда ике ел рәттән район сабантуе батыры булган Киекле авылы егете Алмаз Заһретдинов, танылган көрәшче Тәлгать Дәүләтшиннар һ. б. урынын алган егет ул Фәнил.

- Синең көчле остазларың да булгандыр инде,- дим Фәнилгә.

- Остазым да, тәнкыйтьчем дә әти булды. Инде чын көрәшче булып җитешсәм дә әти һаман да мине өйрәтә, кайчак каты итеп шелтәли дә...

Югыйсә, улы инде үзе ир уртасы кеше. Әлмәт физкультура техникумы, аннан читтән торып физкультура институтын тәмамлап, теоретик белемне дә шактый туплады, башта СПТУда мастер рәвешендә, соңгы елларда ДЮКФП директоры сыйфатында үзе үк дистәләгән яшь көрәшче дә тәрбияләде... Ата белән улның җан тартуы, йөрәк сиземләве, интуиция тәэсир итәдер, күрәмсең, бу очракта. Әнә Фәнил кызы Айгөлне шулай карашыннан аңлый бит. Икенче класста гел 5легә генә укучы Айгөл җиңел атлетика белән дә шөгыльләнә, чаңгы спорты белән дә мавыга. Кечесе - ике яшьлек Айсинәсе дә нәкъ әтисе кебек хәрәкәтчән, җитез. Әниләре Дания сикереп, үрмәләп борчу тудырасыз дип ачуланып та куя кайчак. Ни эшләмәк кирәк, ана бит. Әнә Фәнилнең әнисе аның өчен ничек борчыла. Сабантуй җитә башласа, улына саулык - сабырлык сорап күпме дога укый. Аның каравы Даниянең мәйдан кырыена басып иренең бил алышканын карап торырга сабырлыгы җитми. Фәнил белән өйләнешкән елларында берничә тапкыр чыкты сабантуйга. Аннары кырт кисте: бармыйм, хет күзем күрмәс дип, өйдә кала торган булды. Ә ата кеше... Чәчләренә чал төшеп, буыннары йомшарса да (аңа бу көннәрдә 60 яшь тула) йөрәге картаймый шул: үзен һаман да яшь чагындагыдай гайрәтле көрәшче итеп сизә, балалары өчен һаман да таләпчән, хәтта бераз кырысрак тәрбияче дә әле ул. Тәртипле булсыннар, йөз кызартмасыннар дип тырыша. Алар инде үзләре әти - әни булып олыгаеп килсәләр дә, күңеле һаман балаларында аның.

**Р.ГИНЯЕВА.**
**Рәсемдә: аталы - уллы Гайнуллиннар.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# Яшүсмернең бәхете бармы?

## Яки бер рейдның тарихы

Сер түгел, балигъ булмаганнар тарафыннан эшләнә торган җинаятьләр саны елдан - ел арта бара. Узган елның ун аенда да шундый 25 җинаять теркәлде. Нәтиҗәдә үсмерләр арасындагы җинаятьчелек 1995 елның шул чорындагыдан 25 процентка күбрәк булды. Бер үк вакытта административ хокук бозулар да ишәя. Шушы вакыт эчендә вак хулиганлык өчен 86 һәм спиртлы эчемлекләр кулланган өчен 182 үсмер яки аларның әти - әниләре җавапка тартылган (ник дисәң, 16 яше тулмаган үсмернең хокук бозуы өчен аның әти - әнисе җавап бирә). Моннан тыш 70 кеше үзләренең балигъ булмаган балаларын тәрбияләү буенча бурычларын үтәмәгән өчен административ төстә җавап тоткан. Ике гаиләдә әти - әниләре ул хокуктан мәхрүм ителгән, тагын бер гаиләгә карата материаллар әзерләнә.

Боларның барысы турында да миңа балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне кисәтү бүлеге (ОППН) начальнигы, милиция майоры Н.Н.Корбанов сөйләде. Бүлек хезмәткәрләре уздыра торган рейдта катнашу турында да аның белән килештек.

Рейдка инспекторлар Илһам Сараев һәм Рәсим Мөхәммәтгалиев белән чыктык. Балигъ булмаганнарга карата утлы корал куллану тыелганга күрә, яныбызда кесә фонареннан башка әйбер юк иде. Машина булмаячагы беленгәч җәяү кузгалдык.

Инспекторлар башта «күз уңындагы» берничә гаиләгә кереп чыгарга булдылар. Андыйлар арасында әти - әниләре укымышлы булып та, гаиләдәге ялган һәм бер - береңә ышанмау шартларын күреп үскән балалары урлашу, аракы эчү юлына баскан, укуларын ташлаган гаиләләр дә бар икән.

Бәхеткә каршы, гадәттә урамнан кайтып керми торган ул балалар бу көнне барысы да өйдә иде. «Әле барысы да алда, иң гаҗәбе подвалларда булачак,- диделәр юлдашларым минем гайрәт чигә башлаганны күреп. - Үсмерләрнең иң күп җыелып ята торган җире шул подваллар. Туңарлык булмагач, анда мәктәпкә бармыйча көннәр буе утырырга да мөмкин».

Чыннан да, подваллар буенча йөреп чыккач үзем өчен шактый ук гаҗәп ачышлар ясадым. Егетләр әйткән «җиләк» («малина») да шактый булып, аны җыючы гына юк иде. Иң элек подваллардагы исерткечтән бушаган шешәләр күплеге исне китерә. Алардан чыгып бу аулак урыннарда елына йөзләрчә литр исерткеч эчелүен чамаларга мөмкин. Хәер, анысын подвалларда «онытып» калдырылган шарфлар, бүрекләр, курткалардан да сизеп була. Тагын бер шаккаттырганы подвалларда төрледән - төрле йорт җиһазлары урнаштырылуы, «Минск», «Восход» мотоциклларының детальләре саклануы булды. Инспекторлар әйтүенә караганда, андыйлары нигездә урланган әйберләр икән.

Ә подвалларда йодтан алып төрле төнәтмәләргә кадәр дарулар да булуын кем ничек аңлый торгандыр инде. Бу аулак урыннарда вакыт - вакыт канга батып «эләгешүләр» вакытында алары да кирәк була торгандыр шул. Канга буялган рәшәткә дә, стеналардагы кан таплары да очраклы түгелдер дип уйларга кирәк. Каныңа исерткеч йөгерсә, яшь йөрәк җилкенми калмый шул инде. Ни эшлисең, бигрәк кырыс заманнар китте шул. Бер подвалны очрашу урыны иткән яшь парны күргәч бу фикерем тагын да ныгыды. Әти - әниләре өйләрендә очрашырга рөхсәт бирмәгәч, шушы сасып беткән подвалда күрешергә мәҗбүрләр, мескеннәр...

Тәбәнәк һәм караңгы булуы өстенә чиркәүдәгечә шәмнәр дә янып торганга күрә, беренче христианнарның бергә җыела торган урыннарын хәтерләтүче бу подваллардан «якты дөньяга» чыккач та үсмерләрнең адәм рәтле тормышын күзәтергә туры килде дип булмый. Әнә аякларында көчкә басып торучы икесе ничек тә бер - берсен тотып калырга тырышып атлаган булалар. Ниятләре якындагы киоскага кадәр барып җитү иде, әмма безгә очрагач милициягә таба атларга мәҗбүр булдылар. Бүлеккә килеп җиткәндә ОППНның өлкән инспекторы, милиция капитаны М.М.Зәйниев дискотекадан тотып алып чыккан кызмача ике үсмер дә аларга кушылды...

Бүлеккә барып кергәч егетләр белән иркенләп сөйләштем. Шулай урамда исереп йөрергә аларны нәрсә мәҗбүр итә соң? Җаваплары бер - буш вакытны файдалы итеп үткәрер урын юк. (Спорт заллары, дискотекалар андыйларга бармый - һәм физик, һәм матди хәлләре мөмкинлек бирми). «Родина» кинотеатры ремонтка ябылганчы анда йөри торган идек, билет та арзан иде, диләр. Ә хәзер бер барыр урын да юк. Эх, шәһәрдә яшьләр өчен бер кафе ачсалар иде... Юкса ресторандагы бәяләрнең янына барырлык түгел бит.

Соңгысына килгәндә, кафе турындагы хыялларыннан бөтенләй өмет өзгәннәр бугай инде яшьләр. Һич югы кинотеатрны тизрәк сафка бастырсыннар иде.

... Яше тулганнарны чыгарып җибәрделәр, ә үсмерләргә карата беркетмә яза башладылар. «Үзенең кешелек дәрәҗәсен хур иткән...» - беркетмәләрнең барысында да шушы бер сүз. Ә бит ул үсмерләрнең берсе дә үзе алай уйламый, бары тик бераз салып алгач үзенең кызу канлылыгын күрсәткән дип кенә саный. Анысын малаен алырга дип килгән әтисе өйгә кайткач яхшылап аңлатыр аңлатуын...

Рейд тәмам. Инде төн уртасы җитеп килә, бүлектә дә кеше азайган һәм чагыштырмача тын. Тик менә «авырлар» исемлегендә йөргән үсмерләр генә йокладымы икән бу төнне? Урам үзенә тартып торганда йокы кайгысымени соң аларда? Ә урам, андагы чарасызлык, яшьләргә барып сугылыр урын булмау аларның барысын да бер өемгә туплый. Барысын ук булмаса да, зур күпчелеген... Шулай булгач, яшүсмерләргә дөрес юлны кем генә күрсәтер соң?!..

**P.S. Бу язма матбугатка әзерләнгәндә ялган аракы белән сату итүче, нигездә аны төнлә һәм яшүсмерләргә сатып ятучы бер хатынны тотулары турында хәбәр килеп иреште...**

**Павел ДОЛГАНОВ.**
**Норлат шәһәре.**

# Раштуа очрашулары

Иске яна ел кичендә шәһәрнең үзәк мәйданы халык белән тулы иде. Балалар таудан шуа, олылар матур бизәлгән чыршыга карап хозурлана, төрле яктан көлү, шаяру, шатлыклы авазлар ишетелә. Бәйрәмчә киенгән халык район мәдәният йортына ашыга.

Ә залда... Тамашачы әкият дөньясына килеп эләккәндәй хис итә үзен. Ярымкараңгы сәхнәнең арткы планында ай күтәрелә, ә идәнгә җиңел кар бөртекләре ява...

Алга таба барысы да Гогольдәгечә барды: Солохо (Ә. Якупова) да анда иде. Җен дә (О.Җиһаншина) мичтән чыкты, аның янына Баш (В.Малыгин), Чуб (С.Минеханов) һәм Дияк (И.Фәйзуллин) та килделәр. Гашыйк утында янучы Вакула (А.Грошев) назлы Оксанага (А.Җәлалова) кәвеш бүләк итте.

Мәдәният бүлеге хезмәткәрләре тулы фантазияләрен эшкә җигеп, Гоголь геройларын бүгенге заман белән бәйләп күрсәтергә омтылганнар.

Тамаша район мәдәният йорты каршындагы «Норлат» халык бию ансамбле катнашында үтте. Спектакль барышында алар күп төрле рәвешкә керергә өлгерделәр. Шулай ук «Родник» җыр һәм бию ансамбле үзешчән сәнгатьтә катнашучылар, җырчылар Ольга Ханнанова, Зөһрә Зарифуллина, Индира Гайсина, Марина Матюшкина, Лилия Мингалимова, Фирдүс Тәмаев тамашачылар яраткан җырларны башкардылар.

Сәгать ярым вакыт сизелмичә дә үтеп китте, кичә фойеда күрәзәлек итү белән дәвам итте. Ә аннары викторинада, уеннарда балалар актив катнаштылар.

Мәдәният йортыннан таралышканда тамашачыларның йөзләре канәгать иде. Раштуа кичәсе ял һәм бәйрәм рухы белән үтеп китте.

**О.ОСИПОВА.**


# Шахмат буенча шәһәр чемпионаты

Аның беренчесы 15 гыйнварда тимер юл клубында башланды. Уеннар чәршәмбе көнне кичке 5 тә, шимбә көндезге 12дә, якшәмбе иртәнге 10да узачак.

Шәхси - команда чемпионаты бер әйләнештә тәгәлләнә. Бер партия өчен һәр уенчыга ике сәгать саф вакыт бирелә. Партияләр башланган көнне тәмамлана. Ярышларда узган чемпионатның барлык призерлары һәм шәһәрнең иң көчле шахматчылары катнаша. Теләге булган һәркемне көч сынашырга чакырабыз.

**А.Костин,**
**шахмат ветераны.**

# Котлыйбыз



Кычытканлы авылында яшәүче әтиебез **Вил Мәгъсум улы Хәммәтвәлиевны** 60 яше тулу белән чын күңелдән котлыйбыз. Нык сәламәтлек, тыныч тормыш, озын гомер телибез.

**Балаларың, киленең, оныкларың исеменнән кызың Гүзәл, киявең Наил.**

# Белдерүләр

**Сәламәтлек саклау үзәк идарәсе**
***Санкт - Петербург шәһәре***
***«Гармония» дәүләт предприятиесе***

**Психология фәннәре кандидаты, АКШта университет тәмамлаган, Нью - Йоркта зур практика узган врач - психолог Игорь Николаевич Березной 1 февральдән шикәр диабеты, бавыр, бөер, колак, борын, бронх, бронх астмасы, ангина, ашказаны язвасы, остеохандроз, радикулит, стенокардия, аритмия, энурез, нейродермит, экзема кебек авырулардан, буыннар авыруларыннан, импотенция, простатит, йокысызлыктан, хатын - кыз авыруларыннан лазер ярдәмендә һәм мануаль терапия буенча дәвалау уздыра, шулай ук алкогольдән һәм тәмәкедән котылырга булыша.**

**Безнең профессиональлегебезне 01730 номерлы дәүләт лицензиясе гарантияли.**

**Дәвалау методикалары авырттырусыз, куркынычсыз һәм Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгында расланган.**

**Дәвалау вакытында чит ил медиклары 1995 елда яхшы дип тапкан магнитлы - инфракызыл «Милта» лазеры, транскраниаль электростимулятор һәм башка җиһазлар кулланыла.**

**Кабул итү 1997 елның 1 февраленнән башлап иртәнге 8 дән кичке 8 гә кадәр НУРБның Советская урамындагы медицина пунктында уздырыла.**

**Дәваланганда бер кабул ителү өчен 40 мең сум түләргә кирәк, 7 - 10 тапкыр килү сорала.**

**Алкоголь һәм тәмәкедән котылырга теләүчеләр өчен бер кабул ителү 100 мең сум, 5 - 7 мәртәбә килергә кирәк.**

## *Сатабыз*



**ВАЗ - 21011, кыйммәт түгел.** Нефтьчеләр коммутаторы аша тел.: 65 - 8 - 37.

***

**Фирма китереп бирү шарты белән силикат кирпеч һәм нигез блоклары сата**. Тел.: 5 - 21 - 14 (кичке 5 тән 9 га кадәр).

***

**Чанада дача йорты.** Первомайская ур., 27 адресы буенча теләсә кайчан мөрәҗәгать итәргә.

***

**Шәһәр уртасында ашыгыч төстә бер бүлмәле фатир.** Советская ур., 185 -56 адресы буенча иртә - кич мөрәҗәгать итәргә.

***

**Шикәр заводы поселогында бер бүлмәле фатир.** Тел.: 5 - 18 - 11.

## *Очрашуга чакырабыз*

**Иске Чаллы урта мәктәбе үзендә укып чыкканнарны 1 февральдә кичке 7 гә очрашу кичәсенә чакыра.**

## Рәхмәт белдерәбез

Безнең сөекле улыбыз һәм энебез Юрийны югалту кайгысын уртаклашкан, аны җирләүдә мораль һәм матди булышлык иткән Хафизов исемендәге КХА, Норлатның 4 нче урта мәктәбе коллективларына, элеккеге класс җитәкчесе А.Г.Бадмацыреновага, 1991 елгы чыгарылыш укучыларына, 74107 нче хәрби часть җитәкчелегенә, туганнарга һәм якыннарыбызга, дусларыбызга, күршеләребезгә һәм танышларыбызга чиксез зур рәхмәтебезне белдерәбез.

**Логиновлар гаиләсе.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 данә. Заказ N 5136.